| | | |
|---|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

7 июнь 2022 ел № 132

**Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында**

«Мәҗбүри пенсия иминияте системасында шәхси (персоналаштырган) исәпкә алу турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 1 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2015 елның 11 августындагы 294 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 12 пунктындагы 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«шәхси (персоналаштырган) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ, шул исәптән электрон документ рәвешендә;».

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" бастырып чыгарырга һәм baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин